**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 15-40 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 июлендәге 2022 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы “Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү турында»гы карарын исәпкә алып, Казан шәһәр Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 33 статьяның 16 таблицасында түбәндәге юллардан соң:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.7.2 | Дини идарә һәм мәгариф | Объект-ларның барлык төрләре | 400 | 50000 | 45 | Билге-ләнмә-гән | Билге ләнмә гән | 3 | 5 | 5» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.12 | Фәнни-җитеш-терү эшчән-леге | Объект-ларның барлык төрләре | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән | Билге-ләнмә-гән» |

1.2. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территориаль зонаны – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектлар зонасын (ОД) (77 номерлы контур) 16:50:290501:9 кадастр

номерлы җир кишәрлегенә карата билгеләп, территориаль зона – сәламәтлек саклау объектларын урнаштыру (ОЗ) (19 номерлы контур) зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.3. әлеге карарның 1.2 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.4. кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 2 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.5. кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 12 августындагы
15-40 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОД - 77**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зоналар**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
| --- | --- | --- |
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | ОЗ | Сәламәтлек саклау объектларын урнаштыру зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешенең зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**